РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22.11.2024** **№15**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының «2025 елга һәм 2026-2027 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге бюджеты турында»

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының " Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026- 2027 елларның план чорына бюджеты турында» карары проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026- 2027 елларның план чорына бюджеты турында» карары проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

- Мөхәмәдиева А.Ә-төркем җитәкчесе;
- Мавлавиева И.М. – төркем әгъзасы;
- Муртазин И.Р.-төркем әгъзасы;
- Гәрәев И.М -төркем әгъзасы;
- Мирсалихов М.М.- төркем әгъзасы;
- Хаҗиев А.Н.- төркем әгъзасы;

- Зәйнуллин И.Р.- төркем әгъзасы;

4. Карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркемгә Ф.И.О, авторның туган елын, адресын күрсәтеп, түбәндәге адрес буенча җибәрелә: ТР, Янурыс авылы, Ленин урамы, 43в нче йорт.

5. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының 2025 елга һәм 2026 - 2027 елларның план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2024 елның 7 декабрендә 14.00 сәгатьтә авыл җирлеге Советының утырышлар залында билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм карар проектына карата гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советына карап тикшерүгә 2024 елның 16 декабренә кадәр кертергә.

7. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда әлеге карарны игълан итәргә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Ә. Мөхәмәдиева